ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ЯДЫГЕРЬСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

# КАРАР

18.04.2024ел №11

Муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен яки аларны арендалау хокукын сату, муниципаль милекне түләүсез файдалануга, ышанычлы идарәгә тапшыру буенча бәйге (аукцион) комиссиясе һәм бәйге (аукцион) комиссиясе составы турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.11, 39.12 статьялары, «Аренда килешүләрен, түләүсез файдалану килешүләрен, милек белән ышанычлы идарә итү килешүләрен, дәүләт яки муниципаль милеккә карата хокуклар күчүне күздә тоткан башка килешүләрне төзү хокукына конкурслар яки аукционнар үткәрү тәртибе һәм күрсәтелгән килешүләрне конкурс формасында сату-алу юлы белән төзергә мөмкин булган мөлкәт төрләре исемлеге турында» Россия Федераль суд приставлары хезмәтенең 2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен яки аларны арендалау хокукын сату, муниципаль милекне түләүсез файдалануга, ышанычлы идарәгә тапшыру буенча бәйге (аукцион) комиссиясе турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен яки аларны арендалау хокукын сату, муниципаль милекне түләүсез файдалануга, ышанычлы идарәгә тапшыру буенча бәйге (аукцион) комиссиясен расларга (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны махсус мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

Ядегәр авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе А.Н.Фәйзуллин

Ядегәр авыл җирлеге
башкарма комитетының
2024 елның 18 апрелендәге
11 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен яки аларны арендалау хокукын сату, муниципаль милекне түләүсез файдалануга, ышанычлы идарәгә тапшыру буенча бәйге (аукцион) комиссиясе**

# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен яки аларны арендалау хокукын сату, муниципаль милекне түләүсез файдалануга, ышанычлы идарәгә тапшыру буенча аукционны әзерләү һәм үткәрү Комиссиясе (алга таба – Комиссия) торгларда күчемсез һәм күчемле муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен, милекне арендалау килешүләрен төзү хокукын, җир кишәрлекләрен сату буенча барлык мәсьәләләрне карауны һәм хәл итүне тәэмин итә торган даими эшләүче киңәшмә органы булып тора.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.11, 39.12 статьяларына, «Аренда килешүләрен, түләүсез файдалану килешүләрен, милек белән ышанычлы идарә итү килешүләрен, дәүләт яки муниципаль милеккә карата хокуклар күчүне күздә тоткан башка килешүләрне төзү хокукына конкурслар яки аукционнар үткәрү тәртибе һәм күрсәтелгән килешүләрне конкурс формасында сату-алу юлы белән төзергә мөмкин булган мөлкәт төрләре исемлеге турында» Россия Федераль суд приставлары хезмәтенең 2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Нигезләмә муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен яки аларны арендалау хокукын сату, муниципаль милекне түләүсез файдалануга, ышанычлы идарәгә тапшыру буенча торглар (аукционнар, бәйгеләр) үткәргәндә Комиссиянең вәкаләтләрен һәм эш тәртибен билгели.

## 2. Комиссиянең вәкаләтләре

2.1. Комиссия торглар үткәрү турында хәбәрләр белән билгеләнгән вакытта түбәндәгеләрне башкара:

2.1.1. Дәгъвачылардан кабул ителгән гаризаларны, аларга кушымта итеп куелган документларны карый, дәгъвачылар тәкъдим иткән документларның дөрес рәсмиләштерелүен тикшерә һәм аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә һәм торглар үткәрү турында хәбәрнамәдә басылган исемлеккә туры

килүен билгели, дәгъвачылардан задаткаларның тиешле хисаптан күчермә (күчермәләр) нигезендә килү фактын билгели;

2.1.2. Дәгъвачыларны аукционда (бәйгедә) катнашучылар дип тану яки гамәлдәге законнарда каралган нигезләр буенча аукционда (бәйгедә) катнаштырудан баш тарту турында карар кабул итә;

2.1.3. Аукцион (бәйге) җиңүчесен билгели.

2.2. Комиссиянең дәгъвачыларның гаризаларын карау нәтиҗәләре турындагы карарлары аукционда катнашугагаризалар кабул итү (дәгъвачыларны торгларда катнашучылар дип тану турында) беркетмәләре белән рәсмиләштерелә.

Комиссиянең аукцион (бәйге) нәтиҗәләре турында карарлары, аның җиңүчесен билгеләп, аукцион нәтиҗәләре турында (торглар нәтиҗәләре турында беркетмәләр) аукцион беркетмәләре белән рәсмиләштерелә.

Беркетмәләргә комиссия утырышында катнашучы комиссия әгъзалары кул куя.

2.3. Комиссия комиссия эшләгән вакытта бирелгән документларның саклануын тәэмин итү, шулай ук гариза биргән затлар турында мәгълүматның конфиденциальлеге һәм бирелгән документларның эчтәлеге өчен җаваплы.

## 3. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен яки аларны арендалау хокукын сату, муниципаль милекне түләүсез файдалануга, ышанычлы идарәгә тапшыру буенча торглар (аукционнар, бәйгеләр) (алга таба – торглар) үткәрү өчен төзелә торган коллегиаль орган булып тора.

3.2. Комиссия утырышлары торглар үткәрү турында хәбәр ителгән срокларда үткәрелә.

3.3. Комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми санының ким дигәндә илле проценты булса, Комиссия үзенә йөкләнгән функцияләрне башкарырга хокуклы.

3.4. Комиссия утырышлары аерым бинада үткәрелә.

3.5. Комиссия әгъзалары утырышларда шәхсән катнашалар һәм комиссия утырышларының беркетмәләренә кул куялар.

3.6. Комиссия утырышлары аның рәисе тарафыннан ачыла һәм ябыла.

3.7. Карарлар ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән кабул ителә. Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка гына ия. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч була.

3.8. Комиссия комиссия эшләгән вакытта бирелгән документларның саклануын, шулай ук гариза биргән затлар турында мәгълүматның һәм бирелгән документларның эчтәлегенең конфиденциальлеген тәэмин итә.

3.9. Комиссия утырышларының нәтиҗәләре тиешле беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләрнең төп нөсхәләре торгларны оештыручыда саклана.

## 4. Комиссиянең функцияләре

Үз бурычларын тормышка ашыру максатыннан Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

4.1. бәйгене үткәргәндә:

- бәйгедә катнашу өчен гаризалар белән конвертларны ачуны һәм электрон документлар формасында бирелгән һәм Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына ярашлы рәвештә бәйгедә катнашу өчен имзаланган гаризаларга керү мөмкинлеген ачуны гамәлгә ашыра;

- бәйгедә катнашучыларны билгели;

- бәйгедә катнашу өчен гаризаларны карау, бәяләү һәм чагыштыруны гамәлгә ашыра;

- бәйге җиңүчесен билгели;

- бәйгедә катнашуга гаризалар белән конвертларны ачу һәм бәйгедә катнашуга электрон документлар рәвешендә бирелгән гаризаларга керү мөмкинлеген ачу беркетмәсен, бәйгедә катнашуга гаризаларны карау беркетмәсен, бәйгедә катнашуга гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсен, шартнамә төзүдән баш тарту турында беркетмәне, бәйгедә катнашырга гариза бирүчене яки катнашучыны бәйгедә катнашудан читләштерү турында беркетмәне алып бара;

4.2. аукцион үткәргәндә:

- аукционда катнашуга гаризаларны карау һәм аукционда катнашучыларны сайлап алуны гамәлгә ашыра;

- аукционда катнашуга гаризаларны карау беркетмәсен, аукцион беркетмәсен, шартнамә төзүдән баш тарту турында беркетмәне, аукционда катнашырга гариза бирүчене яки катнашучыны аукционда катнашудан читләштерү турында беркетмәне алып бара.

## 5. Комиссия составы

5.1. Комиссия составы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана. Комиссия кимендә биш әгъзадан тора, алар арасында: Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре, шулай ук комиссия әгъзалары.

5.2. Торглар нәтиҗәләре белән кызыксынучы затлар Комиссия әгъзалары була алмый.

## 6. Комиссиянең хокуклары

Комиссия, үзенә йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен, түбәндәгеләргә хокуклы:

6.1. Торгларда катнашу өчен дәгъва итүчеләрнең гаризаларын һәм документларын карау;

6.2. Дәгъвачылардан торгларда катнашу өчен задаткаларның тиешле хисаптан (хисаплардан) күчермә (күчермәләр) нигезендә килү фактын билгеләргә;

6.3. Гамәлдәге законнарда каралган очракларда торгларны үткәрелмәгән дип тану турында карарлар кабул итәргә.

## 7. Комиссия әгъзаларының бурычлары

7.1. Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә бурычлы:

7.1.1. үз эшчәнлегендә әлеге Нигезләмә таләпләренә таянып эш итәргә;

7.1.2. Комиссия утырышларында шәхсән катнашырга;

7.1.3. үз бурычларын үтәгәндә билгеле булган мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга.

7.2. Рәис, рәис урынбасары һәм комиссия әгъзалары дәгъвачыларны торгларда катнашучылар дип тану турында беркетмәгә кул куялар һәм кабул ителгән карарларның гамәлдәге законнарына туры килүе өчен җаваплылык тоталар.

7.3. Комиссия рәисе:

7.3.1. Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхсән җаваплылык тота, шулай ук:

7.3.2. Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм торглар үткәргәндә гамәлдәге закон таләпләрен, шулай ук әлеге Нигезләмәне үтәүне тәэмин итә;

7.3.3. Комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

7.3.4. утырышны хокуклы дип игълан итә яки, Комиссия әгъзаларының кирәкле саны булмау сәбәпле, аны күчерү турында карар чыгара;

7.3.5. тикшерелә торган мәсьәләләрне карау тәртибен игълан итә;

7.3.6. Комиссия утырышларының беркетмәләренә кул куя;

7.3.7. торгларда җиңүчене игълан итә;

7.3.8. гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Комиссия эше белән бәйле башка гамәлләрне тормышка ашыра.

7.4. Комиссия рәисе урынбасары, рәис булмаганда, рәис вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

7.5. Комиссия секретаре түбәндәгеләрне башкара:

7.5.1. Комиссия әгъзаларына комиссия утырышын үткәрү көне, урыны һәм вакыты турында комиссия утырышы көненә өч көн кала хәбәр итә;

7.5.2. Комиссия утырышларының беркетмәләрен алып бара һәм аларны тиешле рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны тәэмин итә;

7.5.3. Торглар дәгъвачыларына Комиссия кабул иткән карар турында хәбәр итә.

## 8. Комиссия карарларына шикаять бирү

Комиссия карарларына гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

## 9. Комиссия әгъзаларының җаваплылыгы

Комиссия әгъзаларыүз бурычларын үтәмәгән өчен (тиешенчә үтәмәгән өчен) дисциплинар, гражданлык-хокукый, административ, җинаять җаваплылыгы тоталар.

Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 18 апрелендәге 11 номерлы карарына 2 нче кушымта

Муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен яки аларны арендалау хокукын сату, муниципаль милекне түләүсез файдалануга, ышанычлы идарәгә тапшыру комиссиясе СОСТАВы

| | |
|---|---|
| Фәйзуллин Айдар Нәҗип улы | Ядегәр авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе; |
| Комиссия рәисе урынбасары: | |
| Вафин Миннихан Кадыйр улы | Ядегәр авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча); |
| Комиссиия әгъзалары: | |
| Әминов Илгиз Госман улы | Ядегәр авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча); |
| Хазиева Разыя Рәсүл кызы | Ядегәр авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча); |
| Вәлиева Гөлназ Фәйзелкәбир кызы | Ядегәр авылы башкарма комитеты секретаре, Комиссия секретаре |